**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.02.2014 № 79

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2014 елның 5 мартында теркәлде, №2237

**2014 елда вакытлыча эшкә**

**урнашу чорында балигъ булмаганнарга**

**һәм эшсез гражданнарга матди ярдәм**

**күләмнәре турында**

“2014-2020 елларга Татарстан Республикасында яшәүчеләргә эшкә урнашуга ярдәм итү” Дәүләт программасын раслау турында” 09.08.2013 ел, №553 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, боерык бирәм:

2014 елда матди ярдәм күләмнәрен билгеләргә:

14 тән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарга вакытлыча эшкә урнашу чорында, аена бер кешегә эшсезлек буенча минималь пособиенең 1,5 тапкырга тигез күләмендә;

түләүле иҗтимагый эшләрдә катнашучы эшсез гражданнарга, аена бер кешегә эшсезлек буенча минималь пособиенең 2,5 тапкырга тигез күләмендә;

эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарга вакытлыча эшкә урнашу чорында, аена бер кешегә эшсезлек буенча минималь пособиенең 2,5 тапкырга тигез күләмендә;

урта һөнәр белемгә ия булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18 дән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарга вакытлыча эшкә урнашу чорында, аена бер кешегә эшсезлек буенча минималь пособиенең 2,5 тапкырга тигез күләмендә;

гомуми белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлап, беренче тапкыр эш эзләүче эшсез гражданнарга вакытлыча эшкә урнашу чорында, аена бер кешегә эшсезлек буенча минималь пособиенең 2,5 тапкырга тигез күләмендә.

**Министр** **А.Р. Шәфигуллин**